**МИНИСТЕРСТВО ЮСТИЦИИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮСТИЦИЯ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ**

**БОЕРЫК**

02.06.2017

№ 01-02/47

г. Казань

Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре территориясендәге иҗтимагый әһәмияткә ия мәсьәләләр буенча коллектив фикер алышу һәм иҗтимагый халәтне чагылдыру, шулай ук иҗтимагый-сәяси характердагы актуаль мәсьәләләр буенча иҗтимагый фикерне белдерү өчен гражданнарның массакүләм катнашуы өчен каралган бердәй махсус билгеләнгән яки махсуслаштырылган урыннар исемлегенә үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы «Яр Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлегенең Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре территориясендәге иҗтимагый әһәмияткә ия мәсьәләләр буенча коллектив фикер алышу һәм иҗтимагый халәтне чагылдыру, шулай ук иҗтимагый-сәяси характердагы актуаль мәсьәләләр буенча иҗтимагый фикерне белдерү өчен гражданнарның массакүләм катнашуы өчен каралган бердәй махсус билгеләнгән яки махсуслаштырылган урыннарның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2013 елның 6 августындагы 01-02/59 номерлы боерыгы белән расланган исемлеген тулыландыру турындагы тәкъдимен исәпкә алып, **боерам:**

1. Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәрендәге иҗтимагый әһәмияткә ия мәсьәләләр буенча коллектив фикер алышу һәм иҗтимагый халәтне чагылдыру, шулай ук иҗтимагый-сәяси характердагы актуаль мәсьәләләр буенча иҗтимагый фикерне белдерү өчен гражданнарның массакүләм катнашуы өчен каралган бердәй махсус билгеләнгән яки махсуслаштырылган урыннарның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2013 елның 6 августындагы 01-02/59 номерлы боерыгы

белән (Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2014 елның 22 августындагы 01-02/323 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) расланган исемлегенә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

4 пунктны үз көчен югалткан дип санарга.

2. Хокукый мәгълүматлаштыру һәм компьютер системалары бүлеге башлыгы А.Г.Сафинга әлеге боерыкны “Татарстан Республикасының рәсми порталы” Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасындагы Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының рәсми сайтына урнаштырырга.

3. Норматив хокукый актларны теркәү һәм Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы эшчәнлеген хокукый тәэмин итү бүлеге башлыгы Э.И.Слепневага әлеге боерыкны дәүләт теркәвенә алырга.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы юстиция министры урынбасары М.М.Ибәтовка йөкләргә.

Министр Л.Ю. Глухова

Килештерүчеләр:

Татарстан Республикасы
юстиция министры урынбасары М.М.Ибәтов

Норматив хокукый актларны теркәү
һәм Татарстан Республикасы
Юстиция министрлыгы эшчәнлеген
хокукый тәэмин итү бүлеге башлыгы Э.И.Слепнева

Җирле үзидарә органнарына
хокукый консультацион-методик
ярдәм күрсәтү бүлеге башлыгы М.А.Пашкова

Боерыкны әзерләде:
Җирле үзидарә органнарына хокукый
консультацион-методик ярдәм күрсәтү
бүлегенең әйдәп баручы советнигы А.Н.Ханеня